Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының

Кәләй авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2022 ел №61

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе хакында» Әлмәт муниципаль районының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Кәләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне кабул итәргә.

2. Әлмәт муниципаль районының Кәләй авыл Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Кәләй авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Әлмәт муниципаль районы Советы белән килешү төзергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кәләй авыл Советы карарын гамәлдән чыгарырга:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» 2021 елның «14» октябрендәге 26 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» 2021 елның «20» декабрендәге 33 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2021 елның «14» октябрендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның «20» гыйнварындагы 36 номерлы;

4. Әлеге карарны Кәләй авылы, Специалистлар урамы, 2Д йорт; Сабанче авылы, Яббаров урамы, 1 йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кәләй
авыл җирлеге башлыгы С.П. Бастылева